ГЛАВА
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.02.2019 № 15

п.г.т. Алексеевское

**“Совет гаскәрләрен**
**Әфганстаннан чыгаруга 30 ел”**
**истәлек медален раслау турында**

1989 елның 15 феврале – совет гаскәрләрен Әфганстаннан чыгару көне, истәлекле дата, ул Россиядә беркемне дә битараф калдырмый. 1979 елның 25 декабреннән 1989 елның 15 февраленә кадәр сузылган әфган сугышы үзенең зурлыгы буенча хәрби бәрелешләр чылбырында тыйнак урынны алып тора, ләкин 1989 елда әлеге вакыйгага халык депутатлары съезды биргән сәяси бәя совет гаскәрләренең чикләнгән контингентын Әфганстаннан чыгару турындагы карарны, үзләренең хәрби бурычларын үтәгәннәрнең батырлыгын кечерәйтеп күрсәткән кебек булса да, “рухи һәм сәяси яктан гаепләүгә лаек”, дип санарга.

Совет гаскәрләрен Әфганстан Демократик Республикасыннан чыгаруның 30 еллыгын бәйрәм итү алдыннан, мәңгелек истәлеккә һәм эшләнгән батырлыкларга хөрмәт йөзеннән

**карар бирдем:**

1. Хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга тапшыру өчен “Совет гаскәрләрен Әфганстаннан чыгаруга 30 ел” истәлек медален расларга (1 нче Кушымта)
2. Совет гаскәрләрен Әфганстаннан чыгаруның 30 еллыгына багышланган истәлек медале турындагы Нигезләмәне расларга (2 нче Кушымта).
3. Социаль мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (Н.П. Чуринга) “Совет гаскәрләрен Әфганстаннан чыгаруга 30 ел” истәлек медален, аңа таныклык бланкларын әзерләүне оештыруны тәэмин итәргә.
4. Советның оештыру бүлегенә (Е.А. Харитоновага) истәлек медален исәпкә алу һәм саклауны, бирүне тәэмин итәргә.
5. Әлеге карар Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый

мәгълүмат порталында веб-адрес (http://pravo.tatarstan.ru) буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне Совет аппараты җитәкчесе А.С. Харитоновка йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы** **С.А.Демидов**

Татарстан Республики
Алексеевск муниципаль
районы башлыгының
12февраль, 2019ел,15 нче
карарына 1 нче кушымта

“Совет гаскәрләрен Әфганстаннан чыгаруга 30 ел”
истәлек медален сурәтләү

32 мм диаметрлы медаль. Билге орден тасмасы белән бизәлгән биш почмаклы колодкага беркетелә. Колодканың беркеткече гади, булавкага охшаган.
Алтын йөгертелгән эмблемалы медальнең уң ягына түбәндәге рәсем төшерелгән:
үзәктән әз генә сулдарак ике сугышчы-интернационалист баскан. Сугышчылар Әфганстан Демократик Республикасы әләме җирлегендә ясалган.
Өстәге контур буйлап нәкъ менә ныгыткыч астында зур хәрефләр белән “30 ЛЕТ” дигән язма бар.
Сугышчылар астында - “АФГАНИСТАН”, Әфганстан Демократик Республикасы әләме җирлегендә «1979-1989» дигән язулар тора.

Медальнең икенче ягы түбәндәге рәсем белән бизәлгән:

өстәге контур буйлап нәкъ менә ныгыткыч астында Мәңгелек ут сурәте.
Өстән аскы якка таба юбилей бүләгенең бөтен түгәрәге эченә диярлек түбәндәге тәртиптә 4 юлга
30 ЛЕТ ВЫВОДА;
СОВЕТСКИХ ВОЙСК ИЗ АФГАНИСТАНА
дигән сүзләр язылган



Татарстан Республики
Алексеевск муниципаль
районы башлыгының 12
февраль, 2019ел.15 нче
карарына 2 нче кушымта

**Совет гаскәрләрен Әфганстаннан чыгаруга 30 ел тулуга багышланган истәлек медале турында**
**Нигезләмә**

1. "Совет гаскәрләренӘфганстаннанчыгаруга 30 ел" истәлекмедале (алга таба – медаль)Әфганстанда сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның сугышчан хезмәтләрен тану максатындаАлексеевск муниципаль районы башлыгы тарафыннан расланган дәүләтнеке булмаган җәмәгать медале булып тора.

2. Медаль беләнТатарстан Республики Алексеевск муниципаль районы территориясендә яшәүче Әфганстанда сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар бүләкләнә.

3. Юбилей медале белән бүләкләү турындагы инициатива белән чыгарга түбәндәгеләр хокуклы:

3.1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарәсе органнары.

3.2.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Әфганстанда һәм Төньяк Кавказдабарган сугыш хәрәкәтләре ветераннарының җирле җәмәгать.

4. Алексеевск муниципаль районы башлыгы юбилеймедале белән бүләкләү турында әлеге Нигезләмәнең 1 нче, 2 нче пунктларында каралган сәбәп буенчаүз инициативасы белән яки әлеге нигезләмәнең 6 нчы пункты нигезендә кертелергә мөмкин булган тәкъдим итү буенча карар кабул итә.

5. Алексеевск муниципаль районы башлыгына юбилей медале белән бүләкләү турында карар кабул итү өчен түбәндәге документлар кирәк:

- язма формада гариза (үтенеч язуы);
- юбилей медале белән бүләкләүгә тәкъдим ителә торган кешеләрнең сугыш хәрәкәтләрендә катнашуы турында мәгълүматлар;
- юбилей билгесе белән бүләкләүгә тәкъдим ителә торган кешеләрнең кыскача биографиясе.

6.Юбилей медале белән бүләкләү Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башлыгы боерыгы белән рәсмиләштерелә.

7. Истәлек медале һәм аның таныклыгын бирүне исәпкә алу максатында Советның оештыру бүлеге тарафыннан истәлек медале белән бүләкләнүчеләрнең реестры алып барыла.

8. Истәлек медале шәхсән бүләкләнүчегә тапшырыла.

9. Истәлек медаленТатарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башлыгы, ул булмаганда аның урынбасарлары, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башлыгы вәкаләт биргән затлар тантаналы һәм хәбәрдарлык шартларында тапшыралар.

10. Истәлек медале белән бер үк вакытта юбилей медаленәТатарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башлыгы кул куйган һәм Алексеевск район Советы гербы белән расланган таныклык та тапшырыла.

11.Истәлек медальләре 2019 елның 1 мартына кадәр тапшырылачак.

12. Истәлек медальләренең дубликатлары һәм аларның таныклыклары дубликатлары бирелми.

13. Истәлек медалекүкрәкнең сул ягында йөртелә.

Россия Федерациясенең дәүләт бүләкләре,Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре булган очракта әлеге билгеРоссия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләреннән астарак тагыла.

14. “Совет гаскәрләренӘфганстаннанчыгаруга 30 ел” истәлекмедален тапшыру социаль ташламалар һәм башка ташламалар бирү яки аның хуҗасына өстенлекләр бирү өчен сәбәп булып тормый.

15. Медаль һәм аның таныклыгыТатарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджеты хисабына ясала. Истәлек медален тапшыру турында хисаплар һәм тапшырылмаган юбилей медальләре Алексеевск район Советының оештыру бүлегендә саклана.

**Советаппараты җитәкчесе** **А.С. Харитонов**